**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19»ноябрь, 2019 ел № 1839

2020 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 12 декабрендәге 1340 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль оешмаларының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны расларга.

2.Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларының «2020 елга Татарстан Республикасы гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирүне тәэмин итү турында хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанс белән тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. С. Шәйхисламовка йөкләргә.

Район башкарма
комитеты җитәкчесе

А. В. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы муниципаль
оешмалары Башкарма комитеты
җитәкчесе карары белән расланды
«__» ___________ 20___ № ____

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер кешегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 92342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 141713 |